ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 5-103/тэ

Җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2016 № 5-74/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2019 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм, көйләнешле оешмаларның планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, 2019 елга җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә озак сроклы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 16.12.2016 № 5-74/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-90/тэ карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2016 № 5-74/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018№ 5-103/тэ карары редакциясендә)

# Җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2017-2019 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | тариф төре | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «РСУ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 290,74 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 306,42 | - |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 303,42 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 313,30 | - |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 313,30 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 338,75 | - |
| 2 | «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТО-1* эшләгән зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 352,49 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 373,23 | - |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 302,54 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 313,03 | - |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 313,03 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 382,35 | - |
| 3 | «Энерготранзит» җаваплылыгы | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | чикләнгән җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТО-42* эшләгән зонасында | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 33,19 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 34,51 | - |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 22,10 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 22,51 | - |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 22,19 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 22,53 | - |
| 4 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте, Казан шәһәренең ЕТО-2* эшләгән зонасында | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 335,71 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 797,48 | - |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 741,78 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 770,05 | - |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 770,05 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 823,39 | - |

<*> - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2018 елның 16 августындагы 658 номерлы боерыгы белән расланган Казан ш. җылы белән тәэмин итү схемасына нигезләнеп билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге